МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.06.2023 Казан ш № 476

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гражданнарның аерым категорияләренә карата гамәлдә булуы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Билгеләргә:

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының гамәлдә булуы шулай ук 2023 елның 31 декабренә кадәр туры килә торган эш эзләү максатында теркәлгән, түбәндәге категорияләрнең берәрсенә караган гражданнар өчен дә кагыла:

а) эштән азат ителү куркынычы янаган гражданнар (оешма бетерелүгә яки шәхси эшкуарның эшчәнлеге туктатылуга, оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләрнең саны яки штаты кыскартылуга һәм алар белән хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгына бәйле рәвештә эштән китәргә җыенучы гражданнар);

б) эш бирүче зат инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы режимына күчерелгән гражданнар;

в) эшне вакытлыча туктатып тору турында карар кабул иткән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

г) үзләренә карата бөлгенлек (банкротлык) турында процедуралар кулланылган эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

д) эш хакын сакламыйча отпуск ялларында булган гражданнар;

е) эш табуда кыенлыклар кичерүче гражданнар;

ж) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданнары;

з) 2022 елның 30 сентябренә кадәр Донецк Халык Республикасы яки Луганск Халык Республикасы гражданлыгына ия булган гражданнар, Украина гражданнары һәм Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, гражданлыгы булмаган затлар.

1.2. Әлеге пунктның 1.1 пунктчасының «а»-»е» абзацларында күрсәтелгән гражданнар, Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы мәҗбүри булган документларга өстәмә рәвештә, категориягә карап, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә эш бирүче тарафыннан бирелгән, түбәндәгеләр турында карар кабул ителүен раслый торган түбәндәге документларның берсен тапшыралар:

оешманы бетерү яки шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекне туктату турында;

оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләр санын яки штатын кыскарту һәм хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгы турында;

эш бирүче тарафыннан тулы булмаган эш вакытын билгеләү турында;

эшләрне туктату яки вакытлыча туктатып тору турында;

хезмәт хакын сакламыйча гына отпусклар бирү турында;

эшчеләрне азат итү буенча чаралар үткәрү турында.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Министр Э.Ә. Зарипова